Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авыл Советы
КАРАРЫ

19 май 2021 ел № 16

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының 2014 елның 5 нояберендәге «Мәмәт авыл Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы ражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Мәмәт авыл Башкарма комитетына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә» турында 114 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль вазыйфа яки контракты буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2021 елның 19 мартында №02-08-02/249 номерлы күрсәтмәсе нигезендә

Мәмәт авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының 2014 елның 5 нояберендәге «Мәмәт авыл Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Мәмәт авыл Башкарма

комитетына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә» турында 114 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге №460 номерлы Указы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта тапшырыла.»;

1.2.Кушымтаның 6 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« в) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта, хатынының (иренең) һәм (яисә) балигъ булмаган балаларының белешмәләр тапшыру елына кадәрге календарь ел дәвамында (алга таба - хисап чоры) алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса.»;

1.3. Карарга кушымтаның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюталар чыганаклары хакында белешмәләр законнарда билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтка урнаштырыла, әгәр шушы белешмәләр сайтта-«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә булмаса, аларбастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла».

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының 2015 елның 20 ноябрендәге «Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының 2014 елның 5 ноябрендәге 114 номерлы «Мәмәт авыл Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Мәмәт авыл Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары үз көчен югалтты дип санарга.

3. Әлеге карарны Мәмәт авылы, Совет урамы, 1 нче йорт, Чупай авылы Совет урамы, 43А йорты, Сәмәрканд бистәсе, Үзәк урамы, 1 нче йорт

территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мәмәт авыл җирлеге башлыгы И.М.Зөбәерова